РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 21 апреле Кукмара ш. № 58

Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

Кукмара районы прокурорының 2021 елның 02 апрелендәге 02-08-01/2021 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы карар **бирде**:

1. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру

тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәне раслау турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 52 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 21 апрелендәге 58 номерлы карарына кушымта

## Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, Кукмара муниципаль районыны муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында Нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә белән «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, Кукмара муниципаль районыны муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе (алга таба – керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) билгеләнә.

2. Әлеге Нигезләмә муниципаль сайлаулар нәтиҗәләре буенча биләү гамәлгә ашырыла торган муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүчеләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

3. Әлеге Нигезләмәдә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар дигәндә Кукмара муниципаль районы Башлыгы, Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Кукмара муниципаль районы Советы депутатлары, Кукмара муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе аңлашыла.

Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә федераль законнар нигезендә расланган белешмә формасы буенча муниципаль

вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырыла.

5. Әлеге Нигезләмәнең 4 пункты белән каралган белешмә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсы (dohod.tatar.ru) ярдәмендә тутырыла һәм Татарстан Республикасы Президентына тапшырыла. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан имзаланган күрсәтелгән белешмәнең күчермәсе кәгазь чыганакта Кукмара муниципаль районында коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.

6. Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элекке эш урыны яисә сайланулы вазыйфаны биләү урыны буенча керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен граждан тарафыннан документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

2) гражданның муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук гражданның муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр;

3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-

бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.

7. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат ел саен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта түбәндәгеләрне тапшыра:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына (31 декабрь) торышы буенча милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

2) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында белешмәләр, шулай ук аларның милек хокукында булган мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына (31 декабрь) аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.

8. Әлеге Нигезләмә нигезендә үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырган граждан муниципаль вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелмәгән (күрсәтелгән муниципаль вазыйфага билгеләнмәгән, сайланмаган), контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнмәгән булса, әлеге белешмәләр аңа язма гаризасы буенча кире кайтарыла.

9. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында алар тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматлар күрсәтелмәгән яки тулысынча чагылдырылмаган йә хаталар бар икәнлеген ачыклаган очракта, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ

номерлы Татарстан Республикасы Законында һәм әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә алар Татарстан Республикасы Президентына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында төгәлләштерелгән белешмәләр (алга таба – төгәлләштерелгән белешмәләр) тапшырырга хокуклы.

10. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан күрсәтелгән белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

11. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән сроклар тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

12. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшырмаган, шулай ук белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне тапшырган өчен, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

13. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшырмау факты яисә объектив сәбәпләр буенча керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмау турында гариза Татарстан Республикасы Президенты билгеләгән тәртиптә каралырга тиеш.